ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

17.04.2026 г.Лениногорск № 30

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында һәм «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясына таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1.16:51:010602:860 кадастр номеры булган, 339 кв.м мәйданлы Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре шәһәр җирлегеге, Лениногорск шәһәре, Октябрь урамы, 158а адресы буенча урнашкан җир участогына карата җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү боерыгы проекты буенча гавами тыңлауларны, 2026 елның 30 апреленә 14.00 сәгатьтә билгеләргә.

2.Җирле үзидарә турында, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

3.Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 04 маеннан да соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында: https://leninogorsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

М.Н. Гирфанов

Глухова О.С.
5-21-21